ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-02-22, факс (85552) 3-13-44, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

ПР-259 17.12.2025

«Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 22 ноябрендәге ПР-241 номерлы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 14.08.2017 №569 карары белән расланган Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр булдырганда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына үзгәрешләр кертү турында", Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 26 сентябрендәге 763 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пункт 6. II бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә.

« II бүлек. Хезмәткә түләүне формалаштыру тәртибе, хезмәткәрләрнең оклад (вазыйфаи оклады, тариф ставкалары) күләме

6. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары 1 нче таблицада китерелә.

1 нче таблица

№ т/б	Хезмәткәрләрнең вазыйфалары	Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда
1	2	3
1	Учреждение җитәкчесе	33 345
2	Учреждениенең оператив дежурные	25 650

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе А.А.Корбангалинага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш.Бариев